**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2021 ел,3 март №31

**Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар бирә:

1.«Апас шәһәр җирлеге советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2017 елның 7 августындагы 78 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

- 1 пунктның 8 пунктчасын үз көчен югалткан дип санарга;

9 пунктчаны 8 пунктча дип санарга;

- түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә:

«2.1.Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра. Җирлек Советы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән белешмәләрне депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры) тапшыру елыннан алдагы һәр ел эчендә, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр хисап чоры дәвамында башкарылган очракта, тапшыра. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Апас шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы**
**Апас шәһәр җирлеге**
**Советы Рәисе Р.Ф. Хисамутдинов**